| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2022 ел Иске Чүпрәле № **134**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында карарга үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 2018 елның 05 апрелендәге 8 номерлы карарына кертергә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш:

«1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела..».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: В.М.Салахутдинова